ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2023 г. Казань № 734-90/тэ-2023

2024-2028 елларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – Зәй ГРЭС тарафыннан Зәй муниципаль районындагы кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык чыганагына тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 15.12.2023 №59-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә, «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Татэнерго» АҖ) филиалы – Зәй ГРЭС тарафыннан Зәй муниципаль районындагы кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык чыганагына календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 кушымтасы нигезендә 2024-2028 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып, тарифлар формалаштыру өчен җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрларын билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2023 № 734-90/тэ-2023
карарына 1 нче кушымта

## 2024-2028 елларга «Татэнерго» АҖ филиалы – Зәй ГРЭС тарафыннан Зәй муниципаль районындагы кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык чыганагына календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Җайга салынулы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| 1 | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсе җитештерелә торган җылылык энергиясе чыганагына (чыганакларына) хуҗа булган җылылык белән тәэмин итүче оешмадан бирелгән җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә тариф | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» АҖ | | | | |
| 1.1.1 | Чыганак – «Татэнерго» АҖ филиалы – Зәй муниципаль районы Зәй ГРЭС | бер ставкалы, сум/куб.м | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 23,43 | - |
| | | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 26,59 | - |
| | | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 26,59 | - |
| | | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 27,71 | - |
| | | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 27,71 | - |
| | | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 28,81 | - |
| | | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 28,81 | - |
| | | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 29,97 | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 29,97 | - |
| | | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 31,17 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2023 № 734-90/тэ-2023 карарына 2 нче кушымта

# Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2024-2028 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Җайга салынулы оешманың аталышы | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Җылы белән тәэмин итүнең ышанычлылык дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ягулыкка чыгымнарны үзгәртү динамикасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | мең сум | % | % | | | |
| 1 | «Татэнерго» АҖ | | | | | | | | |
| 1.1 | Чыганак – «Татэнерго» АҖ филиалы – Зәй муниципаль районы Зәй ГРЭС | 2024 | су | 3 899,46 | – | 0 | - | - | - |
| | | | пар | - | – | 0 | - | - | - |
| | | 2025 | су | - | 1 | 0 | - | - | - |
| | | | пар | - | 1 | 0 | - | - | - |
| | | 2026 | су | - | 1 | 0 | - | - | - |
| | | | пар | - | 1 | 0 | - | - | - |
| | | 2027 | су | - | 1 | 0 | - | - | - |
| | | | пар | - | 1 | 0 | - | - | - |
| | | 2028 | су | - | 1 | 0 | - | - | - |
| | | | пар | - | 1 | 0 | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге